**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлегенең Рантамак авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рантамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) Рантамак авылынын Вахитов урамы;
- Рантамак авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Рантамак авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- «Сарман» район газетасында Рантамак торак пунктында некрологларны бастыру;
- Рантамак авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу.
- Рантамак авылында яшәүче хезмәткәрләрне терекләндеру буенча хезмәт курсәтуе (печәнне чабу).

3. Әлеге карарны Рангазар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълуматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Шарипова